КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 27 апрель г.Казань № 399

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елның III – IV кварталларында һәм 2021 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән табиб-белгечләренә, клиника-лаборатория диагностикасы табибларына, фельдшерлык-акушерлык пунктлары мөдирләренә – фельдшерларына, шулай ук фельдшерлык-акушерлык пунктлары патронаж фельдшерларына, акушерларына, шәфкать туташларына Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары бирү тәртибе» 2014 ел, 25 февраль, 120 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елның III – IV кварталларында һәм 2021 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән табиб-белгечләренә, клиника-лаборатория диагностикасы табибларына, фельдшерлык-акушерлык пунктлары мөдирләренә – фельдшерларына, шулай ук фельдшерлык-акушерлык пунктлары патронаж фельдшерларына, акушерларына, шәфкать туташларына Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары бирү тәртибе» 2014 ел, 25 февраль, 120 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 5 август, 557 нче; 2018 ел, 15 сентябрь, 784 нче; 2019 ел, 19 март, 191 нче; 2019 ел, 28 август, 709 нчы; 2020 ел,

20 июль, 609 нчы, 2021 ел, 21 май, 358 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2020 елның III – IV кварталларында һәм 2021 елда» сүзләрен «2021 елның III – IV кварталларында һәм 2022 елда» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта татар текстында «гамәлгә ашыру өчен 2021 елда» сүзләрен «гамәлгә ашыру өчен 2022 елда» сүзләренә алмаштырырга, «2020 елның III – IV кварталларында һәм 2021 елда» сүзләрен «2021 елның III – IV кварталларында һәм 2022 елда» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта:

икенче абзацта «2021 елда гамәлгә ашыру тәртибе» сүзләрен «2022 елда гамәлгә ашыру тәртибе» сүзләренә алмаштырырга, «2020 елның III – IV кварталларында һәм 2021 елда» сүзләрен «2021 елның III – IV кварталларында һәм 2022 елда» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «2020 елның III – IV кварталларында һәм 2021 елда» сүзләрен «2021 елның III – IV кварталларында һәм 2022 елда» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2020 елның III – IV кварталларында һәм 2021 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән табиб-белгечләренә, клиника-лаборатория диагностикасы табибларына, фельдшерлык-акушерлык пунктлары мөдирләренә – фельдшерларына, шулай ук фельдшерлык-акушерлык пунктлары патронаж фельдшерларына, акушерларына, шәфкать туташларына 2021 елда Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары бирү тәртибендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2021 елның III – IV кварталларында һәм 2022 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән табиб-белгечләренә, клиника-лаборатория диагностикасы табибларына, фельдшерлык-акушерлык пунктлары мөдирләренә – фельдшерларына, шулай ук фельдшерлык-акушерлык пунктлары патронаж фельдшерларына, акушерларына, шәфкать туташларына 2022 елда Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары бирү тәртибе»;

1 пукнтта «2021 елда гамәлгә ашыру шартлары» сүзләрен «2022 елда гамәлгә ашыру шартлары» сүзләренә алмаштырырга, «2020 елның III – IV кварталларында һәм 2021 елда» сүзләрен «2021 елның III – IV кварталларында һәм 2022 елда» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«күрсәтелгән медицина оешмасында табиб-белгеч вазыйфасында медицина оешмасы белән хезмәт килешүе төзелгәннән соң биш елдан да ким булмаган вакыт эчендә, Россия Федерациясе гражданлыгын алган чит ил гражданы булган табиб-белгечкә карата эшләү йөкләмәсен кабул итү – аны конкурс җиңүчесе дип тану турында карар кабул ителгән көннән (эшләгән вакытны санаганда табиб-белгеч тарафыннан хезмәт функциясен (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 106 һәм 107 статьяларында каралган ял вакытыннан тыш, авыруның булмавы) үтәмәү вакыты исәпкә алынмый);»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе гражданлыгын алган чит ил гражданы булган табиб-белгеч тарафыннан 2014 елдан конкурсны игълан итүгә кадәр чорда төп эш урыны шартларында медицина оешмасы белән хезмәт килешүе төзү.»;

8.1 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) алдагы хисап чоры өчен Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең «Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан Сәламәтлек саклау өлкәсендә федераль статистик күзәтүне оештыру өчен аларны тутыру буенча күрсәтмәләр белән федераль статистик күзәтү формаларын раслау турында» 2021 елның 20 декабрендәге 932 номерлы боерыгы белән расланган «Медицина оешмасы турында мәгълүматлар» 30нчы федераль статистик күзәтүнең еллык формасыннан өземтә;»;

әлеге карар белән расланган 2020 елның III – IV кварталларында һәм 2021 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән табиб-белгечләренә, клиника-лаборатория диагностикасы табибларына, фельдшерлык-акушерлык пунктлары мөдирләренә – фельдшерларына, шулай ук фельдшерлык-акушерлык пунктлары патронаж фельдшерларына, акушерларына, шәфкать туташларына Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары бирү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү тәртибендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2021 елның III – IV кварталларында һәм 2022 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән табиб-белгечләренә, клиника-лаборатория диагностикасы табибларына, фельдшерлык-акушерлык пунктлары мөдирләренә – фельдшерларына, шулай ук фельдшерлык-акушерлык пунктлары патронаж фельдшерларына, акушерларына, шәфкать туташларына Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары бирү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү тәртибе»;

1 пунктта «2020 елның III – IV кварталларында һәм 2021 елда» сүзләрен «2021 елның III – IV кварталларында һәм 2022 елда» сүзләренә алмаштырырга;

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин